ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЕШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423761, Аешавылы, Ленин ур., 34б йорт.

СОВЕТ АИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423761, село Аишево, ул. Ленина, дом 34б.

---

**КАРАР**
**« 12» октябрь 2020 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№6**

**Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 31.07.2020 ел, 263-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлеге Советының 2016 нчы елның 20 июнендәге 12 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлегендә бюджет процессы нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-«2. Авыл җирлеге Советының тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм бюджет турында закон проектын (карарларны) закон чыгару (вәкиллекле) органына карауга керткәннән соң кабул ителгән норматив-хокукый актлары агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә, агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә чираттагы финанс елында исәпкә алына.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Аеш авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга»

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Аеш авыл җирлеге Советы белән рәислек итүче Ахатов Д.Р.